*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

# ТЫЛСЫМ+

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

№7 (61) Апрель, 2024 нче ел

2024 ГОД СЕМЬИ

2024 ГОД НАУЧНО-ТЕХНОЛОГИЧЕСКОГО РАЗВИТИЯ В ТАТАРСТАНЕ ТАТАРСТАНДА ФӘННИ-ТЕХНОЛОГИК ҮСЕШ ЕЛЫ




**Халык моңы —**
**синең моңың**
**булды,**
**Халык күңеле —**
**синең күңелең.**
**Ил гомере, халык**
**гомере кебек**
**Озын булсын,**
**шагыйрь, гомерең!**
***Шәүкәт Галиев***

**Бу санда**


*Гимназия сулышы* 2

*Җиһанда – яз сулышы* 3

*Табигать - уртак йортыбыз* 3

*Шигъри тәлгәшләр* 4

*Китап укыган бала акыллы, белемле, чиста күңелле була* 4



## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### Белеме бар - меңне егар. Афәрин, Зәринә!




17-19 нчы апрель көннәрендә Казан шәһәрендә татар теле һәм әдәбиятыннан XI Халыкара олимпиада үтте. Әлеге олимпиадада районыбыз данын яклап 11 укучы катнашты. Катнашучылар татар теле һәм әдәбиятыннан булган белемнәре буенча телдән һәм язмача биремнәр үтәделәр, проектлар якладылар. Гимназиянең 10 нчы сыйныф укучысы Зәринә Мирсалихова призёр булды. Укытучысы - Зилә Зөфәр кызы Авзалова.

### 26 нчы апрель - бөек шагыйребез Габдулла Тукайның туган көне!






26 апрельдә бөек шагыйребез Габдулла Тукайның туган көнендә, татар халкы Туган тел көнен билгеләп үтә.

Башка бәйрәмнәр һәм истәлекле даталар белән беррәттән, бу көн һәркайсыбызның күңелендә аерым урын биләп тора. “Туган телеңне онытсаң, рухыңны югалтырсың...” – дип язган шагыйрь. Туган телен белмәгән кеше үз халкыннан да, милли тамырларыннан да аерыла, туган җиренә дә ят була.

Гимназия укучылары да бу көнне, традиция буларак, татар халык шагыйре Габдулла Тукайга багышланган истәлекле чараларда катнашып, шагыйрь иҗатына багышланган күргәзмәләр белән танышып, шигырьләр укып билгеләп үтелде.

Мәлләтамак авылының Тукай урамында шагыйрьнең бюстын ачу тантанасы һәм районкүләм бәйрәм чарасы узды. Гимназия укучылары Г.Тукайның шигырьләрен сөйләделәр, аның сүзләренә язылган җырлар башкардылар, үзләре иҗат иткән шигырьләр, җырлар тәкъдим иттеләр.

### «Мин - милләтемнең киләчәге, горурлыгы» исемле смотр-конкурсы үтте







Мөслим гимназиясендә "Мин - милләтемнең киләчәге, горурлыгы" дип исемләнгән бәйгенең финал туры узды. Бәйгедә балалар бакчасыннан - 7, мәктәпләрдән 7 укучы өч төрле ярышта көч сынашты. Һәрберсе үз милләтенең телен, гореф-гадәтләренең үзенчәлеген чагылдырган төрле номерлар күрсәтте.

Әлеге бәйгедә Мөслим гимназиясенең 1 нче а сыйныфы укучысы Микаелян Арман җиңүче булды. Укытучысы - Ләйсән Габбас кызы Мортазина.

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ




1961 нче елның 12 нче апрелендә Җир орбитасына дөньяда беренче кеше белән космик корабль-спутник чыгарыла. Шул вакыттан бирле бу көнне Россиядә Космонавтика көне, ә дөньяда кешенең космоска очу көне булараk билгеләп үтәләр.

Гимназиянең 11 нче сыйныф укучылары Космонавтика көненә багышланган чара үткәрделәр. Укучылар космос турында бик күп кызыклы фактлар сөйләделәр, әлеге тема буенча викторина һәм уеннар үткәрделәр. Һәр сыйныф тәҗрибәләр һәм экспериментлар тәкъдим итте.

Чарада 9-11 нче сыйныф укучылары һәм лаеклы ялдагы укытучыбыз Сәяхова З.М. катнашты, ул барысын да космонавтика көне белән котлады.

Гимназия укучылары Юрий Гагаринның космоска очуын бәйрәм итүгә багышланган "Гагарин елмаюы" акциясенә кушылды.



### Җиңүчеләр һәм призерларга – өстәмә баллар

КФУда укучыларның Н.И. Лобачевский исемендәге IX Бөтенроссия фәнни конференциясенең йомгаклау этабы үтте. Әлеге конференция 1972 елдан бирле уздырылып килә. Быел анда Россия һәм Бәйсез дәүләтләр берлеге илләреннән барлыгы 1704 тикшеренү һәм проект эшләре килгән. Йомгаклау этабына 1120 эш үткән.

Конференциядә гимназиянең 11 нче сыйныф укучысы, газетабызның редакторы Минһаҗева Камилә дәрәҗәле I урынны яулады. Укытучысы - Гөлшат Морат кызы Мирзаморатова.



### “Театр - яктылыкка, нурга илтә”

"Мәктәптә Театр" проекты кысаларында Мөслим гимназиясенең 1 нче б сыйныфы укучылары "Күбәләк" балалар бакчасындагы нәниләргә "Тылсымлы көз" исемле театральләштерелгән тамаша тәкъдим иттеләр.Балалар үз рольләрен бик яхшы башкардылар. Театр коллективы җитәкчесе: Фәхертдинова Ләйсән Әхмәтгаян кызы.

Шулай ук "Кунелле сәхнә" театр түгәрәге әгъзалары, "Театр яктылыкка, нурга илтә" муниципаль проекты кысаларында, Г. Гыйльманның "Көмеш тарак" әсәрен сәхнәләштерделәр. Җитәкчесе: Авзалова Зилә Зөфәр кызы.

### Гимназиядә проект эшчәнлеге

Ел саен укучылар апрель аенда үзләренең проект эшләрен тапшыралар.

Проект сыйфатлы булсын өчен сентябрь аенда ук тема сайлый башларга кирәк.

Һәр проект мөстәкыйль тикшеренү күнекмәләрен (проблемаларны куюю, мәгълүматны җыю һәм эшкәртү, экспериментлар үткәрү, алынган нәтиҗәләргә анализ ясау) эшләүгә юнәлтелгән, иҗади сәләтләрне һәм логик фикерләүне үстерүгә ярдәм итә.

Укучыларны проект эшчәнлегенә җәлеп итү - укучыларның төп белем бирү программасын үзләштерүнең планлаштырылган метапредметлы нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган уку-укыту эшчәнлегенең мотивациясен һәм эффективлыгын арттыру юлларының берсе.



# ҖИҺАНДА - ЯЗ СУЛЫШЫ

*Мөслим гимназиясенең 3 нче в сыйныфы укучылары яза*

## Ыкта боз китте

Яз да килеп җитте. Быел кар кинәт кенә эреде һәм язгы ташулар көчле булды. Язгы ташу сулары белән көрәшү быел безнең Мөслимдә дә күзәтелде. Елгадагы сулар болыннарга таралды. Бик матур күренеш. Без гаиләбез белән Ыкта боз киткәнен карарга бардык.

***Сираева Ралина***

## Көймә йөздерәбез

Менә яз килде. Кошлар да җылы яктан кайттылар. Көннәр озыная, ә төннәр кыскара. Карлар эреп беткәч, беренче чәчәкләр - умырзаялар чыга. Кояш нурлары нык җылы һәм якты. Елгада бозлар китә, сулар ага. Балалар гөрләвектә көймәләр йөздерә.

***Хәсәнов Ринас***

## Күңел сөенә

Яз - табигатьнең сихри бер ел фасылы. Яз көнендә саф һавада йөрүе үзе бер рәхәт. Кешеләр кышкы калын киемнәрен салып, җиңелчә киенеп йөри башлыйлар. Чөнки көннәр җылыта, кояш кыздыра.

Табигатьнең яшәргәнен күреп куңелләр сөенә. Мин язны яратам, чөнки тиздән җәй җитә дигән дәрт барлыкка килә.

***Җәпбарова Әминә***

## Бөреләр уята

Яз - ул табигатьнең кышкы йокыдан уяну вакыты.

Бөтен табигать җанланды. Без дә малайлар белән рәхәтләнеп урамда уйныйбыз. Көймә йөздерәбез. Бутый киеп суның тирәнлеген үлчибез. Кошлар кайтуына сыерчык ояларын ясап элəбез.

***Хаҗиев Тимур***

## Боз китә

Язның беренче ае – март җитүгә, табигатьтә үзгәрешләр көннән-көн арта. Көпшәк кар астында су җыела, аннан ул су сыеша алмыйча юл ярып агып китә. Кечкенә гөрләвекләр бер-берсенә кушылып, язгы ташу барлыкка килә. Ул юлында очраган бар нәрсәне үзе белән агызып алып китә.

***Харисов Илдан***



## Яз – яңа тормыш

Буген иртән торып тәрәзәне ачкач, мин сөенечтән сүзсез калдым. Тышта чын яз иде. Календарьда түгел, ә урманда яз!

Март ае безне бураннары, юеш карлары, суыклары белән үртәп торды. Ә монда яз. Чын яз! Кояшның җылы нурлары минем битемне кытыклый күзне камаштыра. Тирә-юньдә табигатьнең үзгәргәне сизелә.

Әнә гөлҗимеш куагына кунган чыпчыклары да минем кебек сөенәләр.

Кешеләр дә икенче төрле, үзгәргән шикелле. Әнә күрше апа да миңа матур итеп елмайды. Ә мин, әлбәттә, аңа җавап итеп, кычкырып исәнләштем. Яз – дәрт, яз – җыр, яз – яңа тормыш.

***Нассер Фирас***

## Һәркем сөенә

Тышта апрель ае. Язның икенче ае булса да, көннәр җылытырга бик ашыкмый әле. Шулай да берничә җылы көн булып алды. Шул арада карлар эреп бетә язды. Авыл урамнарына көчле ташулар төште.

Ниһаять, яз хәбәрчеләре – сыерчыклар да килде. Алар агач башларына кунып матур итеп сайрыйлар. Яз килүгә алар да сөенәләр.

***Муллагалиев Илдан***

## Җәйге каникулны көтәм

Язгы җылы көннәр башланды. Урамда карлар эри. Кошлар туган якларына әйләнеп кайталар. Яр буйларында беренче чәчәкләр күренә башлады. Тиздән агачлар яфрак ярырлар. Бөтен тирә-юньгә яз исе таралыр.

Язны без бик яратабыз, чөнки тиздән җәйге каникул җитә.

***Бәдретдинов Самир***

# ТАБИГАТЬ - УРТАК ЙОРТЫБЫЗ









Әйләнә-тирә мохитне саклау кешелек алдында торган иң мөһим проблемаларның берсе. Табигатьне саклау бүгенге заманның иң мөһим бурычларыннан санала. Бу бурыч глобаль характерга ия һәм аны барлык илләр тырышлыгы белән генә хәл итәргә мөмкин. Экология айлыгы кысаларында гимназиядә эшләп килүче, биология укытучысы Бариева Л.Ф. җитәкчелегендәге “Экодоблесть” экологик отряды иң беренче чиратта экологияне фән буларак өйрәнүгә зур әһәмият бирә. Шулай ук алар экология өлкәсендә фәнни эшләр, тикшеренүләр, күзәтүләр алып баралар. Бу отрядта шөгыльләнүче укучылар бөтенроссия, республикакүләм акцияләрдә катнашып урыннар алалар.

17 апрельдә "Проросток" экологик проекты кысаларында Мөслим гимназиясенең 8 нче а сыйныф укучылары питомникта чыршы үсентеләрен җыярга ярдәм иттеләр.

## ШИГЪРИ ТӘЛГӘШЛӘР



***Хасанова Асылъяр***
***4 нче б сыйныфы укучысы***

### Укытучым

Исәнмесез, килдегезме диеп,
Каршы ала безне һәркөнне.
Беләсезме, ул укытучы безнең -
Һәммәбезгә бик тә кадерле.

Ул акыллы, сабыр һәм сөйкемле
Көләч йөзле, батыр йөрәкле.
Кирәк чакта таләбен дә куя,
Кирәк чакта аңлый күңелне.

Бик бәхетле яшә, укытучым,
Без бит Сезне хөрмәт итәбез.
Сәламәтлек теләп, рәхмәт әйтеп,
Көн дә өйгә кайтып китәбез.

### Мин татар

Татар минем әнием дә,
Татар минем әтием.
Бабамны да татар итеп,
Сайлаган шул әбием.
Гаиләмдә һәммә кеше,
Сөйләшә туган телдә.
Ничек күңелле, рәхәт,
Яшәве Туган илдә.
Мин саклармын ахыргача,
Телемнең чисталыгын.
- Мама, папа! – дип әйтмичә,
Нәселем горурлыгын.
Хөрмәтем зур урыска да,
Мари, чуваш, уртмуртка.
Килештереп, телне бозып,
Калмаек без хурлыкка.

## КИТАП УКЫГАН БАЛА АКЫЛЛЫ, БЕЛЕМЛЕ, ЧИСТА КҮҢЕЛЛЕ БУЛА

*Галимнәр һәр татар баласы укырга тиешле 100 китап исемлеген төзегән. Китапларның беразын булса да укучылар укысын иде дигән теләктә исемлекне тәкъдим итәбез.*

### Югары сыйныф укучыларына:

51. Разил Вәлиев. Мирас / Кояшлы жыр.
52. Марсель Галиев. Нигез / Ак абагалар.
53. Тәлгать Галиуллин. Сәет Сакманов.
54. Наис Гамбәр. Ачык калган тәрәзәм… (җыентык)
55. Рәдиф Гаташ. Гөлләр су сорый (җыентык).
56. Таҗи Гыйззәт. Чаткылар / Ташкыннар.
57. Аяз Гыйләҗев. Яра / Балта кем кулында? / Йәгез, бер дога…
58. Муса Җәлил. Моабит дәфтәрләре.
59. Ркаил Зәйдулла. Мәгарә / Ил (җыентыклар).
60. Зөлфәт. Йөрәгемне былбыл чакты (җыентык).
61. Галимҗан Ибраһимов. Адәмнәр.
62. Гаяз Исхакый. Зөләйха / Олуг Мөхәммәд.
63. Хисам Камал. Үлгәннән соң яздым.
64. Шәриф Камал. Курай тавышы / Чит илдә.
65. Камил Кәримов. Ком сәгате.
66. Кол Шәриф. И күңел, бу дөньядыр (җыентык).
67. Флүс Латыйфи. Ишелеп төшкән бәхет / Хыянәт.
68. Мәдинә Маликова. Шәфкать.
69. Зиннур Мансуров. Җәрәхәтле йөрәк җылырак (җыентык).
70. Мөхәммәт Мәһдиев. Торналар төшкән җирдә / Фронтовиклар.
71. Туфан Миңнуллин. Ай булмаса, йолдыз бар / Әниләр һәм бәбиләр.
72. Фәрваз Миңнуллин. Балта явызлар кулында (мәкаләләр җыентыгы)
73. Мөхәммәт Мирза. Тере су (җыентык).
74. Газинур Морат. Түбә (җыентык).
75. Рафаэль Мостафин. Өзелгән җыр эзеннән.
76. Ринат Мөхәммәдиев. Сират күпере.
77. Җәмит Рәхимов. Батырша.
78. Әхмәт Рәшит. Сөембикә/ Колшәриф.
79. Фоат Садриев. Кыргый алма әчесе.
80. Хәсән Сарьян. Бер ананың биш улы.
81. Факил Сафин. Гөлҗиһан / Биек тауның башларында.
82. Кадыйр Сибгатуллин. Әйтте шагыйрь (җыентык).

***Башы март санында***

83. Саҗидә Сөләйманова. Тормыш, исәнме!
84. Гурий Тавлин. Афәт.
85. Һади Такташ. Мәхәббәт тәүбәсе.
86. Кәрим Тинчурин. Зәңгәр шәл.
87. Рафаил Төхфәтуллин. Йолдызым.
88. Нурихан Фәттах. Кырык дүртнең май аенда / Кичү.
89. Ренат Харис. Чехов базары / Исемсезләр.
90. Мөсәгыйть Хәбибуллин. Сөембикә-ханбикә һәм Иван Грозный / Атилла.
91. Зөлфәт Хәким. Гасыр моңы.
92. Айдар Хәлим. Сагыш китабы…/ Өч аяклы ат.
93. Шәриф Хөсәенов. Зөбәйдә – адәм баласы / Мәхәббәт сагышы.
94. Фатих Хөсни. Авыл өстендә йолдызлар / Чыбыркы.
95. Зиннур Хөснияр. Кышлаган үгез / Кичү/ Трагедиягә өч билет.
96. Лена Шагыйрьҗан. Божра вә Хөҗрә (җыентык).
97. Фаил Шәфигуллин. Ак маңгайлы бүреләр / Өй салуның ние бар.
98. Илдар Юзеев. Мәхәббәт китабы / Сандугачлар килгән безгә.
99. Миргазиян Юныс. Табу һәм югалту / Юлда уйланулар.
100. Фәнис Яруллин. Кыйгак-кыйгак каз кычкыра / Кайту.

ТЫЛСЫМ+
Апрель, 2024 нче ел
№7 (61)
*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

**Баш мөхәррир:** Солтанова Г.М.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Минһаҗева Камилә
**Корректорлар:** Минһаҗева Диләрә
**Корреспондентлар:** Насырова Мәрьям, Замалова Зәринә
**Дизайнер:** Садриев Илназ
**Компьютерда җыючылар:** Латыпов Илназ, Хәертдинов Ранис

***2014 нче елдан айга бер тапкыр нәшер ителә***
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Формат:** А4 (А3)
**Тираж:** 100